Тәрбия

# Зиратларга юлны онытмыйк!



Зиратны чистартуда балалар да катнашты.



Өмәдә актив катнашучыларның берсе - мөфти Талип хәзрәт Яруллин.

Динебез Ислам мөселман кешесеннән барлык җирдә дә чисталык таләп итә. Ә безнең татарда гомер-гомергә пакьлек беренче урында булган. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа с.г.в. да бу сыйфатларга аеруча игътибар иткән.

Динебез Исламга тугры булган адәмнән өч нәрсә таләп ителә - пакьлек, Исламга ышану һәм динебезгә тугрылык.

Самарада язларын һәм көзләрен җирләр коры чакта зиратларда өмәләр уздыру гадәти хәлгә әйләнеп бара. Яңа гына өлкә мөфтияте тәкъдиме буенча Самараның Мехзавод бистәсендә урнашкан татар зиратында каберләрне тәртипкә китерү буенча өмә үткәрелде. Анда “Нур” мәдрәсәсе шәкертләре, дин әһелләре, яшьләр һәм өлкәннәр дә катнашты. Барлыгы 100 кеше җыелды.

Зиратта кыйшайган кабер ташларын турайттылар, сукмакларны чистарттылар, кипкән үләннәрне җыйдылар, корыган агачларны кистеләр һәм төяп чүплеккә ташладылар.

Көне буе эшләп арыгач, барчасы да Җәмигъ мәчетенә чәй эчәргә кайттылар. Өмәчеләр каршында мөфтиебез Талип хәзрәт Яруллин нотык тотты, үтемле вәгазен сөйләде, теләкләрен белдерде.

Мөфтинең яшьләр һәм җәмәгатьчелек белән эшләүче урынбасары Радик Газизов соңгы айларда башкарылган гамәлләргә тукталды. Аның чыгышыннан берничә фикер:

- Соңгы вакытта яшьләрнең активлыгы үсә. Өмәдә аларның катнашуы - үзенә бер уңай хәл. Бу бер тәрбия чарасы. Зиратка аталарның уллары белән килүе - үзе генә дә асыл күренеш. Димәк, буыннар чылбыры өзелмәгән. Самара татарларында милли йөзебезне саклауда өмет бар.
- Март аеннан башлап юрист Дамир Шәһидуллин бушлай юридик киңәшләрен бирә.
- “Яктылык” мәктәбендә футбол командасын оештырдык.
- Ярлыларга кием-салым таратылды.

«һәр мәхәллә мөселманнары үз мәнфәгатьләрен үзләре кайгыртырга тиеш», - диде Уфадан килгән Әхмәт хәзрәт Әхмәров.

Чәй табынында яшьләр тарафыннан теләкләр дә белдерелде. Алар фикеренчә, башка төбәкләрдәге имамнарны чакырып вәгазь сөйләтергә, яшьләр белән спорт чаралары уздырырга кирәк.

Таһир ага Мамышев тәкъдиме буенча, яшьләр белән эш алып барыр өчен Җәмигъ мәчете каршында яшьләр шурасы сайланды.

*“Нур” мәдрәсәсе ректоры*
**Али СӨЛӘЙМАНОВ.**

# Әдәп вә хая

ӘДӘП — тәрбия, гүзәл әһлак, нәзакәтлелек димәктер.

ХАЯ — оялу, Аллаһыдан куркып, начар эшләрдән саклану, тартыну димәктер.

Мөселман булган кеше өчен иң мөһим нәрсәләрнең берсе — әдәп вә хаядыр. Әгәр кешеләрдә әдәп вә хая, Аллаһы Тәгаләдән курку вә социаль контроль булмаса, дөнья тормышының тәртибе бозылыр иде. Кеше эшләгән хата вә гөнаһларыннан оялмаса, башкалардан тартынмаса, Аллаһыдан курыкмаса, аны начар вә ямьсез эшләрдән туктатып булмас иде. Ул вакытта мәмләкәтләр дә, явыз кешеләр кулында калып, рәхәтлек вә тынычлык бетәр, тормышның тәме китәр иде.

Әдәпле кеше башкалар белән яхшы яшәр, олыларны хөрмәт итәр, кешеләргә рәхим-шәфкать күрсәтер. Андый кеше үзен түбәнәйтә торган хәрәкәтләрдән ерак торыр. Мондый эшләргә очраса, оялыр, бите кызарыр һәм вөҗданы газапланыр. Бу тойгыларга ия һәм хуҗа булган кеше әдәпле вә өстен кеше, дип санала.

Әдәп вә хая барлык кешеләрдә дә бертөрле булмый. Кайбер кешеләр ялгышлык белән генә, белми яисә сизмичә, берәр хата эшләсәләр, көннәр буе оят кайгысыннан котыла алмыйлар. Кайберләре исә зур гөнаһлар, гафу ителмәслек хаталар эшләсәләр дә, исләре китми. Чөнки алар, кызганычка, әдәп вә хаяларын, вөҗдан тойгыларын югалтканнар. Шуның өчен дә, Ислам дине буенча, әдәп вә хая кешеләрне ямьсез эшләрдән туктаткан бер калкан, зур гөнаһлардан саклаучы чара дип кабул ителә.

Ислам дине кануннары буенча кешегә һич кенә дә гөнаһ эшләргә ярамый. Ләкин, кемгә дә булса, берәр сәбәп белән, гөнаһ исәпләнгән берәр эш эшләргә туры килсә, аны барлык кеше күз алдында кылырга ярамый. Чөнки начар вә ямьсез эшләр, кешедән кешегә иярә торган бер хасталыктыр. Шуның өчен дә, әгәр кеше хаталык кылса, аны, башкаларга начар үрнәк булмасын өчен, әйләнә-тирәдәгеләргә күрсәтергә ярамый.

Пәйгамбәребез бер хәдисендә болай дигән: «Оялмаган кеше теләгәнен эшләсен». Димәк, башкалардан оялмаган кеше һәртөрле начар эшләргә дә сәләтле. Гөнаһлы кеше кылган гөнаһлары өчен, һичшиксез, тиешле җәзасын күрәчәк. Пәйгамбәребез бер хәдисендә болай аңлата: «Кешеләрдән оялмаган Аллаһыдан да оялмас».

Кешеләрнең оялуы ике төрле була:

— Аллаһыдан оялу;

— кешеләрдән оялу.

Аллаһыдан оялу кешеләрдән оялудан да өстен, чөнки Аллаһыдан оялу кешеләрне һәртөрле явызлыклардан вә усаллыклардан туктатыр.

***Риза ФӘХРЕТДИН.***

# Һәрнәрсәнең парлы булуы - могҗиза

Аллаһы Коръәндә: «һәр нәрсәне: җир үстергән үсемлекләрне, кешеләрне һәм кешеләр белми торган нәрсәләрне парлы итеп бар итүче Аллаһы һәр кимчелектән пакьтер» («Йәсин», 36).

Бу аятьтә «әзуәҗ» сүзе кулланыла. Бу сүз берничә мәгънәгә ия:

1. Ир һәм хатын җенесеннән булган нәрсәләр.

2. Бер-берсенә капма-каршы булган нәрсәләр (антонимнар), мәсәлән, ак-кара, эссе-суык, изгелек-явызлык, аврлык-җиңеллек, көн-төн һ.б.

3. Бер-берсенә пар булган нәрсәләр: мәсәлән, ике пар канат, ике аяк, ике кул, ике күз һ.б.

Без бернинди аврлыксыз бу дөньяда һәрнәрсәнең парлы, берберсенә капма-каршылыклар белән бар ителгәнен күрәбез. Хәтта кешенең баш мие дә ике ярымшардан тора. Шуңа да карамастан, алар бербөтенне тәшкил итәләр. Хәтта электра утының януы өчен дә плюс белән минусның булуы кирәк.

Аллаһы бу аятьтә һәрнәрсәне һәм хәтта кешеләр белмәгән нәрсәләрне дә парлы, ирле-хатынлы һәм бер-берсенә капма-каршы итеп бар итүе хакында безгә хәбәр итә. Аллаһы бу галәмдә барлык нәрсәләрне төрле-төрле, парлы итеп бар итсә дә, Ул Үзе бер ялгызы, Аның пары да, мисалы да, тиңе дә юктыр. Ул болардан бөек һәм пакьтер.

1933 елда квантовая физика фәнenә нигез салучы физик Поль Дирак табигатьтә барлык нәрсәләрнең дә парлы булулары хакында ачыш ясый. Бу ачышы өчен ул Нобель премиясенә ия була. Ачыш «Аннигиляция һәм парларның барлыкка килүе» исемен ала. Бу ачышта ул һәрбер әйбернең аннан үзгәре булган каршы әйбере (антивеществосы) барлыгын исбатлый. Мәсәлән, электроннарның тискәре зарядка ия булучы антивеществосы, уңай зарядка ия булган протоннары бар. Галәмдәге бөтен асыл кисәкчәләрнең каршылыклы кисәкчәләре бар. Антивещество да асыл веществоның массасына ия, ләкин тискәре зарядлар белән. Материя белән каршы материя катышу сәбәпле, аларның тискәре зарядлары да кушыла һәм шул сәбәпле энергия барлыкка килә.

Коръән җиргә 7 нче гасырда иңдерелде. Кешеләрнең әле бу хакта бернинди дә белемнәре юк иде. Әммә аятьләрдә галәмдә барлык нәрсәләрнең дә парлы икәнлеге хакында ачыктаначык әйтелә.

***Марат хәзрәт СӘЙФЕТДИНОВ.***
***(Мөселман календареннан)***


## Игътибар!

«Ислам-Нур» газетасына язылу дәвам итә.

**Аңа Самара өлкәсенең һәр почта бүлегендә язылырга мөмкин.**

**Индекс – 52381.**

